**КАРАР**

**05 июнь 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында** (2022 елның 18 декабрендә 3 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 05 июнендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына (2022 елның 18 декабрендә 3 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пункка киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә:

Саз-Тамак авылының Ленин урамындагы 96 нчы йорт янындагы чишмә янында урнашкан бүрәнә беседканы Байлангар авылы Сабантуе уздырыла торган урынга күчерергә һәм урнаштырырга ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 530 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 266.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 264 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына (2022 елның 18 декабрендә 3 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены

карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пункка киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә:

Саз-Тамак авылының Ленин урамындагы 96 нчы йорт янындагы чишмә янында урнашкан бүрәнә беседканы Байлангар авылы Сабантуе уздырыла торган урынга күчерергә һәм урнаштырырга ( проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин